Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Арча муниципаль берәмлеге
Арча шәһәре
Башкарма комитеты
422000, ТР, Арча ш., Совет мәйданы, 27
тел. 3-15-25, 3-12-35

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Арча муниципаль берәмлеге
Арча шәһәре
Башкарма комитеты
422000, ТР, Арча ш., Совет мәйданы, 27
тел. 3-15-25, 3-12-35

# КАРАР

**9 сентябрь 2022 ел** **№ 119**

**«2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру» муниципаль программасын раслау турында**

«Энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру турында, һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 23 декабрендәге 261-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Арча шәһәре башкарма комитеты карар бирде:

1. «2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру» муниципаль программасын кушымта нигезендә расларга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Арча шәһәре башкарма
комитеты җитәкчесе Р.Ф. Касыймов

Арча шәһәре
башкарма комитетының
9 сентябрь 2022 ел, №119
карарына кушымта

**«2022 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру» муниципаль программасы**

Арча шәһәре

| | |
|---|---|
| 1. Программаның исеме | «2022-2025 елларга «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру» муниципаль программасы |
| 2. Программа эшләүнең хокукый нигезләре | - «Энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру турында, һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы Федераль закон, 25 статья. Дәүләт яки муниципаль берәмлек катнашындагы оешмалар һәм эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан энергияне сак тотуны һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыруны тәэмин итү;<br>- «Энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру өлкәсендә региональ һәм муниципаль программаларга таләпләр турында» 2009 елның 31 декабрендәге 1225 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары;<br>- «Энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелек өлкәсендә региональ, муниципаль программаларны үстерү өчен кулланыла ала торган энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелек өлкәсендәге чараларның якынча исемлеген раслау турында» Россия Икътисади үсеш министрлыгының 2010 елның 17 февралендәге 61 номерлы боерыгы;<br>- «Энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыруның максатчан күрсәткечләрен исәпләү методикасын раслау турында, шул исәптән чагыштырма шартларда» Россия Минрегионының 2010 елның 07 июнендәге 273 номерлы боерыгы. |
| 3. Программаны раслау датасы | 09.09.2022 ел |
| 4. Программаның максаты | Энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру чараларын гамәлгә ашыру исәбенә энергетик ресурслардан рациональ файдалануны тәэмин итү. |
| 5. Программаның бурычлары | -энергияне сак тоту белән идарә итү буенча оештыру-хокукый чаралар комплексын үткәрү, шул исәптән энергетик ресурсларны кулланганда энергетик нәтиҗәлелекне характерлый торган күрсәткечләр системасын булдыру, аларны мониторинглау, шулай ук мәгълүмат җыю һәм анализлау;<br>-ягулык - энергетик ресурсларны экономияләү;<br>-кулланыла торган энергетик ресурсларның бөтен күләмен исәпкә алуны тәэмин итү;<br>-ягулык-энергетик балансларын алып баруны оештыру;<br>-энергетик ресурслар өчен түләү чыгымнарын киметү. |
| 6. Программаны гамәлгә ашыру сроклары | 2022-2025 еллар |
| 7. Программаның көтелгән нәтиҗәләре | - Администрациядә һәм урамнарны яктырту системаларында электр энергиясен экономияләү;<br>- Энергияне сак тоту белән кызыксынуны арттыру;<br>- Коммуналь ресурслар өчен түләүгә җирле бюджет чыгымнарын киметү. |

| | |
|---|---|
| **8. Программаның күләме һәм финанслау чыганаклары, шул исәптән еллар буенча** | Программаны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү чыганагы - җирле бюджет.<br>Муниципаль программаны гамәлгә ашыруга бюджет ассигнованиеләре күләме 297 мең сум тәшкил итә, шул исәптән: |
| | 2022 елда - 0 мең сум;<br>2023 елда - 99 мең сум;<br>2024 елда - 99 мең сум;<br>2025 елда - 99 мең сум;<br>2022-2025 елларда Программа чараларын финанслау күләмнәре һәм структурасы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең бюджет проектын төгәлләштерү нигезендә социаль-икътисади үсеш фаразларын эшләгәндә төгәлләштерелә. |
| **9. Программаны гамәлгә ашыруны мониторинглауның төп механизмнары** | «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә энергияне сак тоту өчен җаваплы итеп (алга таба - җаваплы зат) 2022 елның 24 августындагы 10 нчы күрсәтмә белән Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары билгеләнде. Ул Программаны гамәлгә ашыруны мониторинглау өчен җаваплы.<br>Программаны гамәлгә ашыру мониторингы түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырылачак:<br>- статистика күзәтүе формалары мәгълүматлары;<br>- Программаны гамәлгә ашыруны квартал саен анализлау мәгълүматлары.<br>Программаны гамәлгә ашыруны мониторинглау энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелекне күтәрү өлкәсендә гомуми һәм хосусый максатчан күрсәткечләрне анализлау, аларның үзгәрү динамикасы һәм алынган күрсәткечләрне анализлау нигезендә гамәлгә ашырыла.<br>Программаны гамәлгә ашыруны мониторинглау нигезендә, кирәк булган очракта, энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру өлкәсендә планлаштырылган максатчан күрсәткечләр, максатлар, бурычлар һәм чаралар төгәлләштереләчәк. |

## 2. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУНЫҢ СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДИ ӨЛКӘСЕНӘ ГОМУМИ ХАРАКТЕРИСТИКА

«Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге үз эченә алты торак пунктны ала.

Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә утыз җиде бюджет оешмасы һәм мәгариф, мәдәният һәм сәламәтлек саклау системаларында муниципаль буйсынудагы учреждение бар («А. Ф. Ежков исемендәге 1нче мәктәп, 2 нче мәктәп, 3 нче мәктәп- балалар бакчасы, 4 нче мәктәп, 5 нче гимназия, 6нчы мәктәп, 7 нче мәктәп), Арчаның 5 нче гимназиясе филиалы- Урта Бирәзә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе, «Арча сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе, «Арча муниципаль районы мәктәп укучылары сарае» муниципаль бюджет учреждениесе,Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе, «Арча Арена» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе, Арчаның 1 нче балалар бакчасы» , Арчаның 2нче балалар бакчасы, Арчаның 4 нче балалар бакчасы, Арчаның 5 нче балалар бакчасы, Арчаның 6 нчы балалар бакчасы, Арчаның 7 нче балалар бакчасы, Арчаның 8 нче балалар бакчасы, Арчаның 9 нчы балалар бакчасы, Арчаның 10 нчы балалар бакчасы, Арчаның 11 нче балалар бакчасы, Күпербаш балалар бакчасы, Арча мәдәният йорты, Айван авыл мәдәният йорты, Күпербаш авыл мәдәният йорты, Плодосовхоз авыл клубы, Күпфункцияле мәдәният үзәге, Арча муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы, 8 нче филиал-Зур Бирәзә авыл китапханәсе, 19 нчы филиал- Күпербаш авылы китапханәсе,34 нче филиал- Иске Айван авыл китапханәсе, 9 нчы филиал- Плодосовхоз авыл китапханәсе, 1 нче филиал-Арча шәһәр китапханәсе, Айван авылында ФАП, Күпербаш авылында ФАП, «Казан арты» Арча тарих-этнография музее, «Әдәбият һәм сәнгать музее» муниципаль бюджет учреждениеләре.

Бюджет оешмаларының исәпкә алу приборлары белән тәэмин ителеше - электр энергиясе буенча- 100%, салкын су - 0%, газ - 100% тәшкил итә.

Торак фонды электр куллануны һәм газ белән тәэмин итүне исәпкә алу приборлары белән 100% җиһазландырылган.

«Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә торак фондын һәм бюджет өлкәсе объектларын җылылык белән тәэмин итү индивидуаль формада.

«Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджет өлкәсе объектларын җылылык энергиясе белән «Тепло-сервис» ҖЧҖ тәэмин итә.

Торак пунктларны су белән муниципаль берәмлек тәэмин итә.

Җирлек куллanучыларын электр энергиясе белән тәэмин итүне «Челтәр компаниясе» АҖ нең Биектау бүлеге гамәлгә ашыра.

Саба районы газ эксплуатацияләү хезмәте газүткәргечләргә хезмәт күрсәтә. Табигый газны төп кулланучылар - торак-коммуналь сектор.

## 3. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ӨЛКӘСЕНДӘ МУНИЦИПАЛЬ СӘЯСӘТ ӨСТЕНЛЕКЛӘРЕ, МАКСАТЧАН КҮРСӘТКЕЧЛӘР, МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ СРОКЛАРЫ ҺӘМ ЭТАПЛАРЫНЫҢ КӨТЕЛГӘН НӘТИҖӘЛӘРЕ ТАСВИРЛАМАСЫ

Программа «Энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»2009 елның 23 декабрендәге 261-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнде.

Энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелекне күтәрү чараларын гамәлгә ашыру исәбенә энергетик ресурслардан рациональ файдалануны тәэмин итү муниципаль программаның максаты булып тора.

Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның максатчан күрсәткечләре:

1. Энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру буенча оештыру чараларын гамәлгә ашыру;

2. Файдаланыла торган энергетик ресурсларны исәпкә алу приборларын тулыландыру;

3. Электр белән тәэмин итү һәм су белән тәэмин итү системасының нәтиҗәлелеген арттыру.

Программаны гамәлгә ашыру түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

- энергетик нәтиҗәлелекне үстерүгә күчүне тормышка ашырырга;
- ягулык-энергетик балансны оптимальләштерергә;
- ТЭР сатып алуга бюджет чыгымнарын киметергә.

Муниципаль программа 2022-2025 елларга исәпләнгән.

Программаны гамәлгә ашыру 2 этапта каралган: беренче этап - 2022-2023 еллар; икенче этап - 2024-2025 еллар.

Программаның икенче этабын гамәлгә ашыру параметрлары 2023 елның ахырыннан да соңга калмыйча төгәлләштерелергә тиеш.

Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның максатчан күрсәткечләре турындагы белешмәләр муниципаль программага 1 нче кушымтада бирелде.

## 4. Муниципаль программаның төп чараларына гомуми характеристика

Муниципаль программаның төп чаралары комплексы - билгеләнгән нәтиҗәләргә ирешүне тәэмин итә торган чараларны финанслау сроклары һәм күләмнәре буенча координацияләнгән система.

Муниципаль программа түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыруга юнәлтелде:

- хокук билгели торган - тиешле өлкәләрдә норматив хокукый җайга салу;
-хокук куллану;
- турыдан-туры администрацияләү һәм идарә итү, шул исәптән җирле бюджет проектларын эшләү.

**Программаның төп чаралары исемлеге:**

| № | Чаралар исеме | Чара буенча чыгымнар исеме |
|---|---|---|
| 1 | Урам яктырткычларын энергия саклаучы лампаларга алыштыру, бюджет оешмаларында энергия саклаучы лампаларны алыштыру | «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты |
| 2 | Энергетик ресурсларны куллану лимитларын билгеләү | Чыгымнар таләп итми |
| 3 | Бюджет оешмаларының тәрәзә уемнарын, нигезләрен җылыту | Чыгымнар таләп итми |

Муниципаль программаны гамәлгә ашыру планы муниципаль программага 2 нче кушымтада күрсәтелде.

## 5. Муниципаль программаны ресурс белән тәэмин итүне нигезләү

Муниципаль программа чаралары җирле бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырылачак.

Муниципаль программаны гамәлгә ашыруга планлаштырылган ресурслар күләмен нигезләү муниципаль финанслар белән нәтиҗәле һәм җаваплы идарә итү өчен шартлар тудырудан гыйбарәт һәм муниципаль программаны гамәлгә ашыру чорына расланган бюджет язмасы нигезендә чираттагы финанс елына һәм план чорына җирле бюджет турындагы карар нигезендә бюджет йөкләмәләренең билгеләнгән лимитлары чикләрендә җирле бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен үз эченә ала.

Муниципаль программаны финанслауның гомуми күләме аны гамәлгә ашыруның бөтен чорында җирле бюджет акчалары исәбеннән 297 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

2022 елда - 0 мең сум;

2023 елда - 99 мең сум; 2024

елда - 99 мең сум;

2025 елда - 99 мең сум.

Финанслау күләме фараз характерында һәм чираттагы елга һәм план чорына «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты турында карар проектын әзерләү кысаларында ел саен төгәлләштерелергә тиеш.

Муниципаль программага
1 нче кушымта

**Программаны гамәлгә ашыру барышын бәяләргә мөмкинлек бирә торган гомуми максатчан күрсәткечләр һәм индикаторлар**

| № т/б | **Күрсәткеч исеме** | Башлангыч күрсәткеч | Күрсәткеч (еллар буенча) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 |
| 1 | «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә кулланыла торган (файдаланыла торган) электр энергиясен исәпләүләр исәпләү приборларыннан файдаланып гамәлгә ашырыла торган электр энергиясе күләме өлеше; | 100% | 100% | 100% | 100% | 100% |
| 3 | Программаны финанслауның гомуми күләмендә энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелекне күтәрү буенча чараларны финанслау өчен кулланыла торган бюджеттан тыш чаралар күләме | Мең сум | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 4 | Электр энергиясен экономияләү | мең кВт-сәг.<br>мең сум | 0,0<br>0,00 | 0,4<br>3,2 | 0,4<br>3,3 | 0,4<br>3,5 |
| | | | | | | |

Муниципаль
программага 2 нче кушымта

**«2022-2025 елларга «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру» муниципаль программасы чараларын гамәлгә ашыру планы**

| № т/б | Чаралар исеме | Финанслау күләме, мең сум | | | | | Финанслау чыганагы | Башкару срогы | Башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Барлыгы | шул исәптән еллар буенча | | | | | | |
| | | | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 10 | 11 | 12 |
| | | | | | | | | | |
| 1 | Урам яктырткычларын энергия саклаучы лампаларга алыштыру, бюджет оешмаларында энергия саклаучы лампаларны алыштыру | 297,0 | 99,0 | 99,0 | 99,0 | | Җирле бюджет | 2022-2025 | Арча шәһәре башкарма комитеты |
| 2 | Энергия ресурсларын куллану лимитларын билгеләү | | | | | | | 2022-2025 | Арча шәһәре башкарма комитеты |
| 3 | Администрация бинасында тәрәзә уемнарын һәм нигезне җылыту | | | | | | | 2022-2025 | Арча шәһәре башкарма комитеты |
| | Барлыгы | 297,0 | 99,0 | 99,0 | 99,0 | | | | |

Муниципал
пролграммага
нче кушымт

2022 елның 1 сентябренә

ЭНЕРГИЯНЕ САК ТОТУ ҺӘМ ЭНЕРГЕТИК НӘТИҖӘЛЕЛЕКНЕ АРТТЫРУ ПРОГРАММАСЫНЫҢ МАКСАТЧАН КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕНӘ ИРЕШҮ ТУРЫНДА ХИСАП

| № | Программа күрсәткечләре исеме | Үлчәү берәмлеге | Программаның максатчан күрсәткечләре | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | план | факт | тайпылышлар |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Муниципаль берәмлек башлыгы

(имза) (тулы имза)

Баш белгеч

(имза) (тулы имза)

Муниципаль программага
4 нче кушымта

2022 нче елның 1 гыйнварына

ЭНЕРГИЯНЕ САК ТОТУ ҺӘМ ЭНЕРГЕТИК НӘТИҖӘЛЕЛЕКНЕ АРТТЫРУ ПРОГРАММАСЫ ЧАРАЛАРЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ТУРЫНДА ХИСАП

| № | Программа чаралары исеме | Чараларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү | | | | Ягулык-энергетик ресурсларны экономияләү | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Күләме, мең сум | | | Табигый чагылышта | | | | Бәя чагылышында | | |
| | | | план | факт | тайпылышлар | саны | | | Үлчәү берәмлеге | план | факт | тайпылышлар |
| | | | | | | план | факт | тайпылышлар | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| | | | | | | | | | | | | |
| **Барлыгы** | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |
| **Чара буенча барлыгы** | | | | | | | | | | | | |
| Чаралар буенча барлыгы | | | | | | | | | | | | |
| Белешмә: Программаны гамәлгә ашыру елы башыннан барлыгы | | | | | | | | | | | | |

Муниципаль берәмлек башлыгы ____________________ ____________________

(имза) (тулы имза)

Баш белгеч ____________ ____________________

(имза) (тулы имза)